СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.12.2017 с. Татарское Бурнашево № 35-158

Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегендә шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары турында

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге халкының тормыш эшчәнлегенең уңай шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән озак сроклы шәһәр төзелеше сәясәтен булдыру һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең җыелма исәпләү күрсәткечләрен һәм мондый объектларның территориаль мөмкин булган максималь дәрәҗәдә рөхсәт ителгән исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы һәм 29.4 статьясы нигезендә эшләнгән Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары турындагы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге башкарма комитеты мәгълүматын тыңлаганнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте

1. Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Бурнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Советының җир мәсьәләләре, төзекләндерү һәм табигать ресурслары буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин